# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 26 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында" 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның беренче өлешендәге сигезенче абзацында "дәүләт күзәтчелеген һәм контролен башкаруга" сүзләрен "федераль дәүләт күзәтчелеген башкаруга" сүзләренә, "контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы" сүзләрен "дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы" сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 статьяда:
а) дүртенче өлештә "эшчәнлек туктатылып торуга яисә эшчәнлек вакытлыча тыелуга бәйле рәвештә" сүзләрен "Россия Федерациясе законнары нигезендә эшчәнлек административ туктатып торылуга яисә эшчәнлек вакытлыча тыелуга бәйле рәвештә" сүзләренә алмаштырырга;
б) унынчы өлештә "дәүләт күзәтчелеген һәм контролен" сүзләрен "федераль дәүләт күзәтчелеген" сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 статьяның өченче өлешендәге өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Күрсәтелүе өчен аккредитация кирәк булган хезмәт күрсәтүләр исемлеге, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче оешмалар туры килергә тиеш-

ле аккредитацияләү таләпләрен үз эченә алган аккредитацияләү кагыйдәләре, аккредитацияләнгән оешмалар эшчәнлеген тикшереп торуны уздыру тәртибе, аккредитацияне туктатып тору яисә чакыртып алу тәртибе хезмәт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.";

4) 14 статьяның икенче өлешендә:

а) унберенче абзацта "даими рәвештә (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүләрен (карауларын)," сүзләреннән соң "башка мәҗбүри медицина тикшерүләрен (карауларын)," сүзләрен өстәргә;

б) ундүртенче абзацта "федераль башкарма хакимиятнең хезмәт турындагы законнарны һәм хезмәт хокукы нормалары булган бүтән норматив хокукый актларны үтәүгә дәүләт күзәтчелеген һәм контролен башкаруга вәкаләтле органнарына," сүзләрен "хезмәт турындагы законнарны һәм хезмәт хокукы нормалары булган бүтән норматив хокукый актларны үтәүгә федераль дәүләт күзәтчелеген башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына," сүзләренә алмаштырырга, "контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы" сүзләрен "дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыручы" сүзләренә алмаштырырга;

в) унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган бүтән норматив хокукый актларны үтәүгә федераль дәүләт күзәтчелеген башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының, эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы бүтән федераль башкарма хакимият органнарының, хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды органнарының вазыйфаи затларының, шулай ук җәмәгатьчелек контроле органнары вәкилләренең хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны тикшерүләр һәм производстводагы бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны тикшерүләр уздыру максатларында тоткарлыксыз керүләрен;";

г) унтугызынчы абзацта "федераль башкарма хакимиятнең дәүләт күзәтчелеген һәм контролен башкаруга вәкаләтле органнарының," сүзләрен "хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган бүтән норматив хокукый актларны үтәүгә федераль дәүләт күзәтчелеген башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының, эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы бүтән федераль башкарма хакимият органнарының," сүзләренә алмаштырырга;

5) 15 статьяның алтынчы абзацында "даими рәвештә (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүләре (караулары)," сүзләреннән соң "башка мәҗбүри медицина тикшерүләре (караулары)" сүзләрен өстәргә;

6) 17 статьяда:

а) икенче өлештә ", аларга капиталь ремонт ясау" сүзләрен төшереп калдырырга, "экспертизасы" сүзе алдыннан "дәүләт" сүзен төшереп калдырырга;

б) өченче өлештә "контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы" сүзләрен "дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыручы" сүзләренә алмаштырырга;

7) 18 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Токсикология (санитария-гигиена, медицина-биология) бәяләмәсе уздырылмаган зарарлы яисә хәвефле матдәләрне, материалларны, продукцияне, товарларны производствода куллану тыела.";

б) икенче өлештә "һәм аларны федераль башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы тиешле органнары белән килештерергә" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

"Имин хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны тәэмин итү эшләрен башкарганда үлчәмнәр бердәйлеген тәэмин итүне дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсенә кертелә торган үлчәмнәргә карата, шулай ук әлеге үлчәмнәр өчен кулланыла торган үлчәмнәр чараларына карата таләпләр үлчәмнәр бердәйлеген тәэмин итү турындагы Россия Федерациясе законнары һәм техник җайга салу турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.";

8) 20 статьяның дүртенче өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Әлеге чаралар исәбеннән имин хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту һәм һөнәри хәвефлелек ихтималларын киметү буенча эш бирүче тарафыннан ел саен тормышка ашырыла торган гамәлләрнең бердәй исемлеге хезмәт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.";

9) IV бүлекнең исемендә "КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ ТИКШЕРЕП ТОРУ" сүзләрен "КОНТРОЛЬ (КҮЗӘТЧЕЛЕК)" сүзләренә алмаштырырга;

10) 22 статьяның исемендә һәм текстында "дәүләт күзәтчелеге һәм тикшереп торуы" сүзләрен "дәүләт контроле (күзәтчелеге)" сүзләренә алмаштырырга;

11) 23 статьяда:

а) беренче өлештә "дәүләт күзәтчелеген һәм контролен" сүзләрен "федераль дәүләт күзәтчелеген" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа икенче өлеш өстәргә:

"Әгәр хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру өчен документация һәм материаллар хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы затлар тарафыннан тапшырылмаган булса, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыруга вәкаләтле органнар үзләренә карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырыла торган органнардан һәм оешмалардан, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнардан, бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан, әгәр әлеге документация һәм

материаллар Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә мондый органнар йә оешмалар карамагында булса, әлеге документацияне һәм материалларны мөстәкыйль соратып ала.";

в) икенче – дүртенче өлешләрне тәңгәл рәвештә өченче – бишенче өлешләр дип санарга;

12) 25 статьяда "дәүләт күзәтүе һәм контроле" сүзләрен "дәүләт контроле (күзәтчелеге)" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 17 мае
№ 25-ТРЗ